3. Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләренә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлыгы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый актлар чыгаруны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

муниципаль вазыйфалар биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлыгы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актларны эшләгәндә әлеге Указга таянырга;

муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлыгы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар чыгаруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 18 март
№ ПУ-265

Татарстан Республикасы
Президентының
2016 елның «18» мартындагы
ПУ-265 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлыгы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлыгы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен билгели.

2. Әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар коррупциягә каршы көрәшү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлыгы барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш.

Хәбәр язма рәвештә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлыгы барлыкка килү турында хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) итеп рәсмиләштерелә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар: Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Россия Федерациясендә Татарстан Республикасының Вәкаләтле вәкиле, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы министры, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органы җитәкчесе – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзасы, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе, Татарстан Республикасы

Хисап палатасы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторы Татарстан Республикасы Президентына кушымта нигезендәге форма буенча төзелгән хәбәрнамә җибәрә.

4. Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе хәбәрнамәсен Татарстан Республикасы Президенты шәхсән үзе карап тикшерә.

5. Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе хәбәрнамәләреннән тыш, Татарстан Республикасы Президентына җибәрелгән хәбәрнамәләрне Татарстан Республикасы Президенты кушуы буенча Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе карап тикшерергә мөмкин.

6. Татарстан Республикасы Президентына яисә Әлеге Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә юлланган хәбәрнамәләр әлеге затлар карары буенча Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясенә (алга таба – Комиссия) җибәрелергә мөмкин.

7. Алар буенча карар әлеге Нигезләмәнең 6 пункты нигезендә кабул ителгән хәбәрнамәләр Татарстан Республикасы Президенты яисә Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе кушуы буенча алдан карап тикшерү өчен Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә (алга таба – Идарә) җибәрелергә мөмкин.

Хәбәрнамәләрне алдан карап тикшерү барышында Идарәнең вазыйфаи затлары хәбәрнамә җибәргән затлардан билгеләнгән тәртиптә анда бәян ителгән вакыйгалар буенча аңлатмалар сорарга һәм билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга соратулар җибәрергә хокуклы.

8. Әлеге Нигезләмәнең 7 пункты нигезендә кергән хәбәрнамәләрне алдан карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Идарәдә аларның һәрберсенә дәлилле бәяләмә әзерләнә.

Хәбәрнамәләрне карап тикшерү барышында алынган хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар хәбәрнамәләр Идарәгә кергән көннән җиде эш көне дәвамында Комиссия рәисенә тапшырыла.

Әлеге Нигезләмәнең 7 пункты икенче абзацында күрсәтелгән соратулар җибәргән очракта, хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар хәбәрнамәләр Идарәгә кергән көннән 45 көн дәвамында Комиссия рәисенә тапшырыла. Әлеге срок озайтылырга мөмкин, ләкин ул 30 көннән дә артып китмәскә тиеш.

9. Хәбәрнамәләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тарафыннан түбәндәге карарларның берсен кабул ителә:

а) хәбәрнамә җибәргән зат вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килми дип танырга;

б) хәбәрнамә җибәргән зат вазыйфаи бурычларын үтәгәндә аның шәхси кызыксынганлыгы мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яисә китерергә мөмкин дип танырга;

в) хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләре үтәлмәгән дип танырга.

10. Әлеге Нигезләмәнең 9 пункты «б» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Президенты Россия Федерациясе законнары нигезендә мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрә яки чаралар күрүне тәэмин итә яисә хәбәрнамә җибәргән затка шундый чаралар күрергә тәкъдим итә.

11. Әлеге Нигезләмәнең 9 пункты «б» һәм «в» пунктчаларында каралган карарлар Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән очракта, ул Татарстан Республикасы Президентына доклад әзерли.

12. Комиссия Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе турында» 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-986 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясенең Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе турындагы нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә хәбәрнамәләрне карап тикшерә һәм алар буенча карарлар кабул итә.

Татарстан Республикасы аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлыгы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында нигезләмәгә кушымта

_______________________________
(документ белән танышу турында билге)

Татарстан Республикасы Президентына
_________________________________
_________________________________
(Ф.И. А.и., биләгән вазыйфасы)

**Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлыгы барлыкка килү турында хәбәрнамә**

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә миндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлык барлыкка килү турында хәбәр итәм (тиешлесенең астына сызарга).

Шәхси кызыксынганлык барлыкка килү өчен нигез булып торучы шартлар: ______________________________________________________________
______________________________________________________________.

Аларны үтәүгә шәхси кызыксынганлык йогынты ясый торган яисә йогынты ясарга мөмкин булган вазыйфаи бурычлар:______________________
______________________________________________________________.

Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ________________________________________
______________________________________________________________.

Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе утырышында әлеге хәбәрнамәне карап тикшерү барышында шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмим) (тиешлесенең астына сызарга).

20___ елның «____»______________ ________________ ________________
(хәбәрнамә җибәргән затның имзасы) (имзаны шәрехләү)

Татарстан Республикасы
Президентының
2016 елның « 18 » мартындагы
ПУ-265 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы, 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-328 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы, 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы һәм 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-988 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында нигезләмәнең 6 пункты «в» пунктчасында һәм 13 пунктында «, акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» 2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-330 номерлы, 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы һәм 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар

тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында нигезләмәнең 6 пункты «в» пунктчасында һәм 12 пунктында «, акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт органнарының рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 19 апрелендәге ПУ-237 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы, 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 14 августындагы ПУ-761 номерлы, 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы һәм 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт органнарының рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәнең 2 пункты «г» пунктчасында «, акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы, 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы һәм 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында нигезләмәдә:

а) 15 пунктның «б» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлыгы барлыкка килү турында хәбәрнамәсе;»;

б) $16^1$ пункттагы дүртенче җөмләне төшереп калдырырга;

в) $16^3$ пункттагы икенче җөмләне төшереп калдырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле $16^4$ һәм $16^5$ пунктларын өстәргә:

«$16^4$. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән хәбәрнамә дәүләт органы кадрлар хезмәтенең

коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча бүлекчәсе яисә дәүләт органы кадрлар хезмәтенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карап тикшерелә, ул хәбәрнамәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәлилле бәяләмә әзерли.

$16^5$. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасы икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне яисә әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәлилле бәяләмә әзерләгәндә дәүләт органының кадрлар бүлекчәсе вазыйфаи затлары мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә биргән дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә уздырырга, аннан язма рәвештә аңлатмалар алырга, ә дәүләт органы җитәкчесе яисә аның махсус вәкаләтләр бирелгән урынбасары билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга соратулар җибәрергә мөмкин. Мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә кергән көннән җиде эш көне дәвамында комиссия рәисенә җибәрелә. Соратулар җибәргән очракта, хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар мөрәҗәгать яисә хәбәрнамәләр кергән көннән 45 көн дәвамында комиссия рәисенә тапшырыла. Әлеге срок озайтылырга мөмкин, ләкин ул 30 көннән дә артып китмәскә тиеш.»;

д) 17 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) 10 көн вакыт эчендә комиссия утырышы вакытын билгели. Шул ук вакытта комиссия утырышы әлеге Нигезләмәнең $17^1$ һәм $17^2$ пунктларында каралган очраклардан тыш, күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән 20 көннән дә соңрак билгеләнелә алмый;»;

е) $17^1$ пунктта «өченче абзацта күрсәтелгән гариза» сүзләрен «өченче һәм дүртенче абзацларда күрсәтелгән гаризалар» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, аңа карата хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү мәсьәләсе карала торган дәүләт хезмәткәре яисә дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче граждан катнашында уздырыла. Комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләк белдерүе турында дәүләт хезмәткәре яисә граждан әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасы нигезендә бирелә торган мөрәҗәгать, гариза яисә хәбәрнамәдә күрсәтә.»;

з) түбәндәге эчтәлекле $18^1$ пункты өстәргә:

«$18^1$. Комиссия утырышлары түбәндәге очракларда дәүләт хезмәткәре һәм граждан катнашыннан башка уздырылырга мөмкин:

а) әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасында каралган мөрәҗәгать, гариза яисә хәбәрнамәдә дәүләт хезмәткәре яисә гражданның комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләк белдерүе турында күрсәтелмәсә;

б) комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләк белдергән һәм утырыш уздырылу вакыты һәм урыны турында тиешле тәртиптә хәбәр ителгән дәүләт хезмәткәре һәм граждан комиссия утырышына килмәсә.»;

и) түбәндәге эчтәлекле $24^3$ пункты өстәргә:

«$24^3$. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасы бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре вазыйфаи бурычларын үтәү вакытында мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килми дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә аның шәхси кызыксынганлыгы мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яисә китерергә мөмкин дип танырга. Бу очракта комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яисә) дәүләт органы җитәкчесенә мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу яисә аны булдырмау буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәре тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләре үтәлмәгән дип танырга. Бу очракта комиссия дәүләт органы җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы кулланырга тәкъдим итә.»;

к) 25 пунктта «21 - 24, $24^1$, $24^2$ пунктлары һәм» сүзләрен «21 - 24, $24^1$ – $24^3$ пунктлары һәм» сүзләренә алмаштырырга»;

л) 32 пунктта «3 көн вакыт эчендә» сүзләрен «7 көн вакыт эчендә» сүзләренә алмаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2010 елның 30 сентябрендәге ПУ-636 номерлы Указының 1 пунктында:

а) беренче абзацта «гражданнар аңа билгеләнгәндә һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) «а» пунктчасында «коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмаларда, әгәр әлеге оешмалар белән дәүләт идарәсенең аерым функцияләре Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, вазыйфа биләргә һәм граждан-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкарырга» сүзләрен «оешмаларда, әгәр әлеге оешмалар белән дәүләт идарәсенең аерым функцияләре федераль законнарда каралган очракларда Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, хезмәт шартнамәсе нигезендә вазыйфа биләргә һәм (яисә) әлеге оешмада граждан-хокукый шартнамә (граждан-хокукый шартнамәләр) шартларында эшләр башкарырга (әлеге оешмага хезмәт күрсәтергә)».

6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексын раслау турында» 2011 елның 23 мартындагы ПУ-142 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 29 ноябрендәге

ПУ-1100 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәреше белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексының 21 пункты «в» пунктчасында «, акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

7. Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында һәм Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы Указында (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы һәм 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән):

а) 1 пунктның «а» пунктчасы дүртенче абзацында «даими нигездә» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 пунктның икенче абзацында һәм 6 пунктта «, акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

8. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе турында» 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-986 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 5 декабрендәге ПУ-1163 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәреше белән) Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясенең Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе турындагы нигезләмәдә:

а) 2 пунктта:

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) Идарәгә кергән:

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның объектив сәбәпләр буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү мөмкин булмавы турында гаризасы;

чит ил дәүләте территориясендә урнашкан чит ил банкларында счетлары (кертемнәре) булган, акча һәм кыйммәтле әйберләре саклана торган һәм (яисә) чит ил финанс инструментлары булган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм тотуны, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Аерым категориядәге затларга Россия

Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм тотуны, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль закон) таләпләрен әлеге чит ил дәүләт законнары нигезендә чит ил дәүләтенең вәкаләтле органнары тарафыннан арест салыну, файдалану тыелу белән бәйле рәвештә яки аның ихтыярыннан яисә аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярыннан башка шартлар белән бәйле рәвештә үтәү мөмкин булмавы турында гаризасы;»;

түбәндәге эчтәлекле «в» пунктчасы өстәргә:

«в) Татарстан Республикасы Президенты яисә Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе карары буенча Комиссиягә кергән вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлык барлыкка килү турында хәбәрнамә, шулай ук дәлилле бәяләмә һәм башка материаллар.»;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» пунктчасында күрсәтелгән гаризалар Татарстан Республикасы Президенты исеменә кертелә.

Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән гариза керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар бирү өчен билгеләнгән вакытта бирелә.

Идарәдә әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән гаризалар һәм хәбәрнамәләр алдан карап тикшерелә һәм карап тикшерү нәтиҗәләре буенча аларның һәрберсенә дәлилле бәяләмә әзерләнә.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункты өстәргә:

«$3^1$. Әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында каралган дәлилле бәяләмә әзерләгәндә Идарәнең вазыйфаи заты Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе кушуы буенча әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» һәм «в» пунктчалары нигезендә гариза яисә хәбәрнамә җибәргән затлардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле аңлатмалар алырга, ә Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе билгеләнгән тәртиптә федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга соратулар җибәрергә мөмкин.

Гаризалар яисә хәбәрнамәләр, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар гариза яисә хәбәрнамә кергән көннән җиде эш көне дәвамында Комиссия рәисенә җибәрелә.

Соратулар җибәргән очракта, хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар хәбәрнамәләр кергән көннән 45 көн дәвамында комиссия рәисенә тапшырыла. Әлеге срок озайтылырга мөмкин, ләкин ул 30 көннән дә артып китмәскә тиеш.»;

г) түбәндәге эчтәлекле $3^2$ пункты өстәргә:

«$3^2$. Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» пунктчасы икенче абзацында күрсәтелгән гаризада һәм аны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча әзерләнгән

дәлилле бәяләмәдә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы биләүче зат тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирмәвенең сәбәбе объектив һәм дәлилле дип санарга мөмкинлек бирүче нигезләр җитәрлек булганда, Комиссия рәисе әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «а» пунктчасында каралган карарны кабул итәргә мөмкин.

Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» пунктчасы өченче абзацында күрсәтелгән гаризада һәм аны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча әзерләнгән дәлилле бәяләмәдә «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм тотуны, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль закон таләпләрен үтәүгә киртә булып торучы шартларны объектив дип санарга мөмкинлек бирүче нигезләр җитәрлек булганда, Комиссия рәисе әлеге Нигезләмәнең $15^1$ пункты «а» пунктчасында каралган карарны кабул итәргә мөмкин.

Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «в» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәдә һәм аны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча әзерләнгән дәлилле бәяләмәдә хәбәрнамә биргән затның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килми дип йомгак ясарга нигезләр җитәрлек булганда, Комиссия рәисе әлеге Нигезләмәнең $15^2$ пункты «а» пунктчасында каралган карарны кабул итәргә мөмкин.

Бәяләмә һәм аның нигезендә кабул ителгән карар Комиссиянең якын арада булачак утырышында Комиссия әгъзаларына җиткерелә. Гариза яисә хәбәрнамә биргән затка кабул ителгән карар турында язма рәвештә, карар кабул ителгән көннән җиде эш көне дәвамында хәбәр ителергә тиеш.»;

д) 8 пунктта «13 - 15 пунктлары белән» сүзләрен «13 - 15, $15^1$ һәм $15^2$ пунктлары белән» сүзләренә алмаштырырга;

е) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» һәм «в» пунктчалары нигезендә гариза яисә хәбәрнамә биргән зат катнашында уздырыла. Комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләк белдерүе турында гариза яисә хәбәрнамә бирүче зат гариза яисә хәбәрнамәдә күрсәтә.»;

ж) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункты өстәргә:

«$9^1$. Комиссия утырышлары түбәндәге очракларда әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» һәм «в» пунктчалары нигезендә гариза яисә хәбәрнамә биргән зат катнашыннан башка уздырылырга мөмкин:

а) гариза яисә хәбәрнамәдә гариза яисә хәбәрнамә биргән затның комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләк белдерүе турында күрсәтелмәсә;

б) комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләк белдергән һәм утырыш уздырылу вакыты һәм урыны турында тиешле тәртиптә хәбәр ителгән гариза яисә хәбәрнамә биргән зат комиссия утырышына килмәсә.»;

з) 15 пунктта «2 пунктның «б» пунктчасы нигезендә» сүзләрен «2 пунктның «б» пунктчасы икенче абзацы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

и) түбәндәге эчтәлекле $15^1$ һәм $15^2$ пунктлары өстәргә:

«$15^1$. Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» пунктчасы өченче абзацында күрсәтелгән гаризаны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә мөмкин:

а) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат тарафыннан «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм тотуны, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль закон таләпләрен үтәүгә киртә булып торучы шартларны объектив дип танырга;

б) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат тарафыннан «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм тотуны, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль закон таләпләрен үтәүгә киртә булып торучы шартларны объектив дип танымау.

$15^2$. Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «в» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләрне карап тикшерү йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә мөмкин:

а) хәбәрнамә биргән зат вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килми дип танырга;

б) хәбәрнамә биргән зат вазыйфаи бурычларын үтәгәндә аның шәхси кызыксынганлыгы мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яисә китерергә мөмкин дип танырга. Бу очракта Комиссия хәбәрнамә биргән затка мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) хәбәрнамә биргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләре үтәлмәгән дип танырга. Кабул ителгән карар турында Комиссия рәисе яки Комиссия секретаре дәүләт органының яисә оешманың Россия Федерациясе законнары нигезендә юридик җаваплылыкка тарту вәкаләте бирелгән вазыйфаи затына хәбәр итә.»;

к) 18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Комиссия карары Комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан кул куела торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.»;

л) түбәндәге эчтәлекле $18^1$ пункты өстәргә:

«$18^1$. Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» һәм «в» пунктлары белән каралган гаризаларда, хәбәрнамәләрдә аларны бирүче затларның Комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләк белдерүе күрсәтелмәгән очракта, Комиссия рәисе карары буенча әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән

мәсьәләләр буенча тавыш бирү Комиссия әгъзаларына сораштыру кәгазьләре, шулай ук башка материалларны җибәрү юлы белән читтән торып уздырыла ала.

Комиссия әгъзасы сораштыру кәгазен тутырган вакытта Комиссия тәкъдим иткән карарны яклап яисә каршы тавыш биреп, үз фикерен белдерергә тиеш. Комиссия әгъзасы кул куйган сораштыру кәгазе аны алган көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, Комиссиягә җибәрелә.

Читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән Комиссия карары әлеге Нигезләмәнең 19 пункты таләпләре нигезендә беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм беркетмәгә кул куелган көннән җиде эш көне дәвамында Комиссия әгъзаларына һәм кызыксынган затларга җибәрелә.»;

м) 21 пунктта «Комиссия утырышыннан соң җиде көн дәвамында» сүзләрен «Комиссия утырышы беркетмәсенә кул куелган көннән биш эш көне дәвамында» сүзләренә алмаштырырга.

---